**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт-хокук идарәсе турында нигезләмәне раслау хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында» 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы Указы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт-хокук идарәсе турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе турында нигезләмәне раслау турында» 2006 елның 15 маендагы ПУ-174 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты актларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 5 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-622 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 4 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 26 июлендәге ПУ-693 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 3 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты указларының аерым нигезләмәләрен үз көчен югалткан дип тану турында» 2013 елның 3 декабрендәге ПУ-1176 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты указларының үз көчен югалткан нигезләмәләре исемлегенең 2 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның

12 декабрендәге ПУ-1091 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 2 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты эшчәнлегенең аерым мәсьәләләре турында» 2019 елның 1 февралендәге ПУ-50 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 2 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым актлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 17 декабрендәге ПУ-889 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 7 пункты.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2023 ел, 16 март
№ 164

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның « 16» мартындагы
 164 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт-хокук идарәсе турында нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт-хокук идарәсе (алга таба шулай ук – Идарә) Татарстан Республикасы Рәисе эшчәнлеген хокукый тәэмин итү максатында төзелгән Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең структур бүлекчәсе булып тора.

2. Идарә үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Рәисе указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында нигезләмәгә, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе боерыкларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Идарә турыдан-туры Татарстан Республикасы Рәисенә һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә буйсына.

4. Идарә турында нигезләмәне Татарстан Республикасы Рәисе раслый.

II. Идарәнең төп бурычлары

5. Идарәнең төп бурычлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе эшчәнлеген хокукый тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе йөкләмәсе буенча Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы киңәшмә һәм консультация органнары эшчәнлеген хокукый тәэмин итү;

Татарстан Республикасында ярлыкау мәсьәләләре комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итү.

## III. Идарәнең төп функцияләре

6. Идарәнең төп функцияләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Рәисе указлары һәм боерыклары, башка хокукый актлар проектларын эшләү буенча Татарстан Республикасы Рәисенә тәкъдимнәр бирү;

Татарстан Республикасы Рәисе йөкләмәсе буенча Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан аларны закон чыгару башлангычы тәртибендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тапшыру өчен закон проектларын әзерләү;

Татарстан Республикасы Рәисе йөкләмәсе буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравындагы закон проектларына Татарстан Республикасы Рәисе бәяләмәләре проектларын әзерләү;

Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы законнарына кул кую (кире кагу) турында тәкъдимнәр әзерләү;

Татарстан Республикасы Рәисе указлары һәм боерыклары проектларын, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе йөкләмәсе буенча Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе боерыклары проектларын кул куюга әзерләү;

Татарстан Республикасы Рәисенә бирелгән Татарстан Республикасы Рәисе указлары һәм боерыклары проектларына аларның законнарга туры килүе яисә килмәве хакында бәяләмәләр әзерләү;

Татарстан Республикасының халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрен хокукый тәэмин итүдә, катнашу, Татарстан Республикасы шартнамәләре һәм килешүләре проектларына аларның гамәлдәге законнарга туры килүе яисә килмәве хакында бәяләмәләр әзерләү;

Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Рәисе указларына каршы килгән очракта, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары гамәлен туктату турында тәкъдимнәр әзерләү;

Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белән хезмәттәшлеген тәэмин итүдә катнашу, шул исәптән Татарстан Республикасы Рәисе йөкләмәсе буенча аның мәнфәгатьләрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советында вәкиллек итү;

Татарстан Республикасы Рәисе мәнфәгатьләрендә суд органнарында вәкиллек итү;

норматив хокукый актлар проектларын әзерләгәндә башкарма хакимият органнары һәм башка дәүләт органнары белән хезмәттәшлек итү;

Татарстан Республикасы законнарының, Татарстан Республикасы Рәисе указлары һәм боерыкларының үз вакытында басылып чыгуын контрольдә тоту;

Татарстан Республикасы Рәисе йөкләмәсе буенча федераль законнар һәм башка норматив хокукый актлар проектларына бәяләмәләр, федераль дәүләт органнары өчен тәкъдимнәр әзерләү;

Татарстан Республикасында ярлыкау мәсьәләләре комиссиясе утырышларында карау өчен материаллар әзерләү һәм утырышлар уздыруны тәэмин итү;

федераль гомуми юрисдикция судларына антлы утырышчылар кандидатлары исемлекләрен төзү һәм Татарстан Республикасы Рәисенә кул куярга бирү, шулай ук әлеге исемлекләргә үзгәрешләр һәм төзәтмәләр кертү;

Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Рәисе указлары һәм боерыклары контроль нөсхәләрен системалаштыру;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең структур бүлекчәләренә хокукый ярдәм күрсәтү, Татарстан Республикасы Рәисе яисә Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе йөкләмәсе буенча Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең структур бүлекчәләрендә әзерләнә торган документлар проектларының гамәлдәге законнарга туры килү-килмәве хакында бәяләмәләр әзерләү;

үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы Рәисе указлары, боерыклары һәм йөкләмәләре, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе боерыклары һәм йөкләмәләре үтәлешен контрольдән төшерүнең максатка ярашлы булу-булмавы хакында бәяләмәләр әзерләү;

Идарә Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе йөкләмәсе буенча башка функцияләрне башкара.

## IV. Идарәнең хокуклары

7. Үзенең бурычларын һәм функцияләрен гамәлгә ашыру өчен Идарә түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең структур бүлекчәләреннән, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратыннан, Татарстан Республикасы Югары Суды, Татарстан Республикасы Арбитраж суды аппаратларыннан, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт органнарыннан, федераль дәүләт органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан билгеләнгән тәртиптә кирәкле материалларны соратырга һәм алырга;

Идарәнең, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы башка дәүләт органнары хокук хезмәтләренең эшчәнлеген камилләштерү буенча Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә тәкъдимнәр бирергә.

V. Идарәнең хезмәттәшлек итү даирәсе

8. Үзенең функцияләрен башкарганда Идарә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Югары Суды, Татарстан Республикасы Арбитраж суды, Татарстан Республикасы прокуратурасы, Татарстан Республикасы дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, федераль дәүләт органнары һәм аларның территориаль органнары, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең барлык структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи затлары белән хезмәттәшлек итә.

VI. Җаваплылык

9. Идарә хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан расланган вазыйфаи регламент нигезендә үзләренә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы.

VII. Идарә эшчәнлеген оештыру

10. Идарәнең структурасы һәм штат саны Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

11. Идарә эшчәнлегенә Татарстан Республикасы Рәисе указы нигезендә вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә торган Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы (алга таба – Идарә башлыгы) җитәкчелек итә.

12. Идарә башлыгы:

Татарстан Республикасы Рәисенә кул кую өчен бирелә торган Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Рәисе указлары һәм боерыклары проектларын, шулай ук Идарә катнашында әзерләнгән башка документларны тиешле дәүләт органнары, вазыйфаи затлар белән килештерә һәм имза куя;

Татарстан Республикасы Рәисе указлары һәм боерыклары проектларын, шулай ук закон чыгару башлангычы тәртибендә Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына бирү өчен Татарстан Республикасы законнары проектларын Татарстан Республикасы Рәисенә тапшыра;

Татарстан Республикасы Рәисе уздырган киңәшмәләрдә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы дәүләт органнары, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан төзелә торган органнар утырышларында Идарә компетенциясенә кергән мәсьәләләрне караганда катнаша, Идарә вәкилләрен билгеләнгән тәртиптә коллегияләр һәм киңәшмәләр эшендә катнашырга җибәрә;

Татарстан Республикасы Рәисе йөкләмәсе буенча законда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Дәүләт Советында һәм аның органнарында, шулай ук суд органнарында аның исеменнән эш йөртә;

Идарә хезмәткәрләре арасында вазыйфаи бурычларны бүлә һәм аларның вазыйфаи регламентларын раслау өчен Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә бирә;

Идарәнең структур бүлекчәләре функцияләрен билгели;

Идарә хезмәткәрләрен вазыйфага билгеләү яисә аларны вазыйфадан азат итү, шулай ук командировкага җибәрү турында Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә тәкъдимнәр бирә;

Идарәгә йөкләнгән бурычларны нәтиҗәле гамәлгә ашыру өчен җаваплы була.

13. Идарә башлыгы вакытлыча эш урынында булмаган чорда Идарә башлыгы вазыйфаларын башкаручы итеп Идарә башлыгы урынбасары яисә Идарәнең вәкаләтле башка бер вазыйфаи заты билгеләнә.

14. Идарә хезмәткәрләре Идарә башлыгы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә.